| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОКАКЕРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ИСКЕ КӘКЕРЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

с. Старые Какерли

Карар

«7» февраля 2017 г. № 46/3

**Законнардагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый норматив актларына мониторинг үткәрү хакындагы Нигезләмәне раслау турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районын Иске Кәкерле авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнарының законнардагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (игълан ителгән) муниципаль хокукый норматив актларга мониторинг үткәрү буенча эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 1. Кушымтада бирелгән Законнардагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый норматив актларына мониторинг үткәрү хакындагы Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районыИске Кәкерле авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнарына:

үзләренең нормалар билгеләү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянырга;

күрсәтелгән Нигезләмәне үтәү буенча җаваплы затлар билгеләп куярга;

җаваплы затлар булып билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи инструкцияләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпләле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге билгеләгән Устав буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге масса-күләм интернет челтәрендә рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольлек итүне үземдә калдырам.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылганнан соң ун көн үткәч үз көченә керә.

Таратстан Республикасы
Чүпрәле районы Иске Кәкерле
авыл җирлеге башлыгы С.А.Хусаинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Кәкерле авыл җирлеге
авыл җирлеге Советының
«7» февраля 2019 г. № 46/3
карары белән расланган

**Законнардагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый норматив актларына мониторинг үткәрү хакындагы Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Законнардагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый норматив актларына мониторинг (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) муниципаль актларның кабул ителешен (игълан ителешен), үзгәртелешен яки көчен югалткан (кире кагылган) дип саналышын тәэмин итү өчен җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләре чикләрендә мәгълүматлар җыю, аларны гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлеген күздә тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3. Мониторинг үткәргәндә җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советы аппаратының юридик бүлеге һәм муниципаль берәмлекнең башка җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итәләр.

4. Мониторинг үткәрү өчен җирле үзидарә органнарында җаваплы затлар билгеләнеп куела.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып:

федераль законнарга һәм республика законнарына туры китерү максатында муниципаль актларның кабул ителүе, үзгәртелүе яки көчен югалткан дип саналуы кирәклеген ачыклау;

муниципаль актлардагы коллизияләрне, каршылыкларны, төшереп калдыруларны, хокукый җайга салудагы кабатлауларны бетерү;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

муниципаль актлардагы коррупциоген факторларны ачыклау;

кирәге калмаган (актуальлелеген югалткан) яки практикада кулланылмаучы муниципаль актларны яки аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокук кулланылышының эффектлылыгын күтәрү; муниципаль актларны реализацияләүнең эффектлылыгын киметүче факторларны ачыклау;

җирле үзидарәнең тиешле бүлекчәләре тарафыннан муниципаль актларның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыруга булышлык итү;

нормалар билгеләү эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү тора.

6. Мониторинг үз эченә:

федераль конституцион законнардагы, федераль законнардагы, Россия Федерациясенең башка закон чыгару актларындагы;

Россия Федерациясе Президенты указларындагы, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларындагы, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларындагы, федераль дәрәҗәдәге башка норматив хокукый актлардагы;

Татарстан Республикасының законнарындагы һәм башка норматив хокукый актларындагы;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставындагы, муниципаль актлардагы үзгәрешләрне җыюны, аларны гомумиләштерүне, анализлауны һәм бәяләүне ала.

муниципаль актлар, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авылы җирлеге Уставын.

7. Мониторинг алып баруга нигез булып:

федераль һәм республика закон чыгару актларына үзгәрешләр кертелү;

муниципаль актларның хокукый җайга салуның аерым сферасында кулланылышын анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

муниципаль актларның җитешсезлеге яки аларны камилләштерү кирәклеге хакында массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматы;

муниципаль актларның камил булмавы хакында гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән, иҗтимагый оешмаларның, фән, хокук яклау оешмаларының һәм башка оешмаларның, шәхси эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгате, шул исәптән түбәндәгеләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләр тора:

Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертелгән муниципаль актларга карата Татарстан Республикасы юстиция министрлыгы үткәргән хокукый экспертиза бәяләмәләрен;

муниципаль актларга аны үткәрергә вәкаләтле булган затлар билгеләнгән тәртиптә үткәргән коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләрен;

җирле үзидарә органнары үткәрә торган конференцияләр, семинарлар, халык тыңлаулары, җәмәгать тикшерүләре һәм башка чараларның йомгаклау документларын.

## II. Мониторингны үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары үз компетенцияләренә кагылган мәсьәләләр буенча мониторингны әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җапаплы затлар белән хезмәттәшлектә үткәрәләр.

Мониторинг үткәрү максатында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат сорап алынырга, Татарстан Республикасының, Россия Федерациясе субъектларының башка муниципаль берәмлекләре тәҗрибәсе өйрәнелергә, эшчәнлекнең башка формалары файдаланылырга мөмкин.

9. Мониторинг:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актларны;

федераль, республика, муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау хакындагы эшләр буенча суд актларын (суд практикасын);

прокурор күзәтчелеге актларын анализлау рәвешендә гамәлгә ашырыла.

10. Мониторинг үткәрү, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, һәм шулай ук, мониторинг йомгаклары буенча башкарылган норма чыгару эшләре нәтиҗәләрен беркетеп кую максатында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кабул иткән җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлары реестрын төзү һәм алып бару тәртибе хакындагы карарына туры китереп алып барылучы муниципаль норматив хокукый актлары реестры файдаланыла.

11. Мониторинг үткәрү процессын гамәлгә ашыруны оптимальләштерү өчен:

«Гарант» мәгълүмати системаларында контрольгә куелган закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларга үзгәреш кертелү турында мәгълүмат булуны;

«Гарант» яки «КонсультантПлюс” мәгълүмати системаларында хокукый җайга салуның тиешле сфераларындагы яңалыклар хакында мәгълүмат булуны;

“Кодекс” мәгълүмати компаниясенең “Региональ закон чыгару эшчәнлеге аналитикасы” автоматлаштырылган мәгълүмати системасында муниципаль актларда законнарга туры килмәүчелекне ачыклаган мәгълүмат булуны тәэмин итүче мәгълүмати системаларның автоматлаштырылган сервислары (аларның операторлары белән контрактлар, килешүләр төзү белән бәйле мөмкинлекләр булганда) файдаланыла.

Мониторинг үткәрү процессын гамәлгә ашыруны оптимальләштерү максатында башка мәгълүмати системалар сервислары файдаланылырга мөмкин.

12. Муниципаль хокукый актларның кабул ителешен (игълан ителешен), үзгәртелешен яки

көчен югалткан (кире кагылган) дип саналышын тәэмин итү өчен мониторинг үткәргәндә әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән беррәттән муниципаль актларның кулланылыш практикасы түбәндәге критерийлар буенча гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларының, ирегенең һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше;

муниципаль актлар кабул ителүенең (игълан ителүенең) кирәклеген билгеләүче зуррак юридик көчкә ия булган норматив хокукый актларның булуы;

җирле үзидарә органының муниципаль актлар игълан иткәндә үз компетенциясе чикләрен үтәүе;

муниципаль актларда коррупциоген факторларның булуы;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның тулылыгы;

хокукый нормалардагы коллизия;

юридик-техник характердагы хаталар булуы;

муниципаль актны кулланганда аның нигезләмәләренең мәгънәсе бозылу;

муниципаль хокукый актны кулланганда законсыз яки нигезсез карарлар, гамәлләр (бер нәрсә дә эшләмәүлек);

норматив хокукый актларны куллану тәҗрибәсе булу;

норматив хокукый актларны куллануда бертөрле тәҗрибә булмау;

муниципаль актка аңлатма бирү мәсьәләләре буенча гаризалар булуы (саны) һәм аларның эчтәлеге;

гариза бирүчеләрнең муниципаль акт тарафыннан җайга салынучы мөнәсәбәтләргә бәйле таләпләренең канәгатьләндерелүе (кире кагылуы) турында законлы көченә кергән суд карарларының булуы (саны);

13. Мониторинг йомгаклары буенча федераль законнарда һәм республика законнарында муниципаль актларның үзгәртелүен таләп иткән үзгәрешләр ачыклaнганда, җирле үзидарә органнары:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актны үз көчен югалткан дип санау турында, яңа муниципаль акт кабул итү турында тиешле муниципаль акт проектлары төзиләр;

муниципаль актларны зуррак юридик көчкә ия булган актларга туры китерүгә юнәлтелгән башка чаралар күрәләр.

14. Федераль һәм республика закон чыгару актларына муниципаль актларның үзгәртелүен таләп иткән үзгәрешләр кертелгәндә мониторинг федераль яки республика актлары игълан ителгән моменттан соң 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» гы Федераль закон билгеләгән срокларда каралырга тиешле прокурор күзәтчелеге актларыннан гайре башка прокуратура мәгълүматы торганда мониторинг алар кергән көннән соң 30 көн эчендә үткәрелә. Күрсәтелгән очракларда мониторинг үткәрүнең йомгаклары хакында мөрәҗәгать итүче затка хәбәр ителә.

Федераль һәм республика закон чыгару актларына үз көченә ерак перспективада керүче үзгәрешләр ачыкланганда, җирле үзидарә органнарының норма билгеләү эшчәнлеге планнарына тиешле корректировка ясау турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт проектын төзү һәм аны кабул итү тиешле федераль һәм (яки) республика закон чыгару актларына үзгәреш кертелгән моменттан әлеге Нигезләмәнең 14 пункты өченче абзацында күрсәтелгән очрактан гайре ике айдан соң булмаган срокта башкарыла.

16. Мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар мониторинг нәтиҗәләре турында җирле

үзидарә органнары җитәкчеләре каршында ай саен, хисап аеннан соң килгән айның 5 числосыннан соңга калмый, хисап тоталар.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турындагы хисап (мәгълүматлар) үз эченә түбәндәгеләрне кертергә тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрүне башкаручылар турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрү периоды турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрүгә нигез булган хокукый җайга салу предметына кыскача характеристика.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турындагы хисап (мәгълүматлар) үз эченә түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актка үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль акт кабул итү, муниципаль актны кире кагу кирәклеге турында рекомендацияләр;

мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән, хокукый мөнәсәбәтләрнең тиешле сферасында хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлтелгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча яңа кабул ителгән муниципаль актлар законнар билгеләгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрелә.

Күрсәтелгән регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган һәм аңа кертелмәгән муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләреннән чыгып, норма чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү һәм хокукый юнәлештәге эшчәнлек өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук җирле үзидарә органнары карамагында булган тиешле хокукый җайга салу сферасындагы муниципаль актларны федераль законнарга һәм республика законнарына үз вакытында туры китерү өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) җаваплылыкта булалар.

20. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кылынган, негатив нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зарар китергән гамәлләр (бер нәрсә дә эшләмәүлек) өчен закон нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җавап тоталар.